Совет Большеачасырского сельского поселения Зеленодольского муниципального района Республики Татарстан

Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Олы Ачасыр авыл жирлеге Советы

РЕШЕНИЕ

КАРАР

22 июль 2020 ел

№247

Татарстан Республикасы Яшел Үзән муниципаль районының «Олы Ачасыр авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең мөлкәт белән идарә итү, алардан файдалану, алар белән эш итү буенча вәкаләтләре өлешен муниципаль милек реестрлары муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында, шулай ук кече һәм урта эшкуарлык субъектларына бирү өчен билгеләнгән мөлкәт исемлеген бастырып чыгару турында

2003 елның 6 октябрендә кабул ителгән 131-ФЗ номерлы Федераль законның «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы законынын 14 һәм 15 статьялары, 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы законы, Татарстан Республикасы Яшел Үзән муниципаль районының «Олы Ачасыр авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Яшел Үзән муниципаль районының Олы Ачасыр авыл җирлеге Советы **карар итте**:

1.Татарстан Республикасы «Яшел Үзән муниципаль районы» муниципаль берәмлегенә мөлкәт белән идарә итү, аннан файдалану, алар белән эш итү, муниципаль милек реестрларын, шулай ук кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына бирү өчен билгеләнгән мөлкәт исемлекләрен бастырып чыгару буенча Татарстан Республикасы Яшел Үзән муниципаль районының «Олы Ачасыр авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге вәкаләтләрен тапшырырга.

2. Яшел Үзән муниципаль районы Башкарма комитетына Яшел Үзән муниципаль районы Олы Ачасыр авыл җирлеге башкарма комитеты белән килешү төзергә.

3. Вәкаләтләрнең бер өлешен гамәлгә ашыруны Яшел Үзән муниципаль районының «Олы Ачасыр авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге бюджетыннан Яшел Үзән муниципаль районы бюджетына бирелә торган бюджетара трансфертлар исәбенә тапшыру гамәлгә ашырыла.

4. Әлеге карарны Интернет челтәренең Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре составындагы Зеленодольск муниципаль районы мәгълүмат сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru), шулай ук мәгълүмат стендларында: Олы Ачасыр авылы, Үзәк урамы, 46 йорт (җирлек хакимияте бинасы), Олы Ачасыр авылы, Кооператив урамы, 26 йорт (авыл мәдәният йорты бинасы) урнаштырырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Олы Ачасыр авыл җирлеге башлыгына йөкләргә.

**Олы Ачасыр авыл жирлеге башлыгы, Совет рәисе** **М.Г. Гатиятуллин**